**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең дәүләт бүләкләре бүлеге турында нигезләмәне раслау хакында**

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе турында» 2023 елның 4 февралендәге ПУ-68 номерлы Указы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең дәүләт бүләкләре бүлеге турында нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының дәүләт бүләкләре бүлеге турында Нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 22 маендагы ПУ-184 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2012 елның 4 июнендәге ПУ-416 номерлы Указына кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Президенты указларына кертелә торган үзгәрешләр исемлегенең 3 пункты;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 26 июлендәге ПУ-693 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты указлары аерым нигезләмәләренең үз көчен югалтуын тану турында» 2013 елның 3 декабрендәге ПУ-1176 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 12 декабрендәге ПУ-1091 номерлы Указына кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Президенты указларына кертелә торган үзгәрешләр исемлегенең 3 пункты;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Президентының аерым актлары үз көчен югалткан дип тану турында» 2022 елның 17 декабрендәге ПУ-889 номерлы Указына кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Президенты указларына кертелә торган үзгәрешләр исемлегенең 9 пункты;

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2023 ел, 03 июль
№ 465

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2023 елның «03» июлендәге
465 номерлы Указы белән
расланды

**Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең дәүләт бүләкләре бүлеге турында нигезләмә**

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең дәүләт бүләкләре бүлеге (алга таба – Бүлек) Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең структур бүлекчәсе булып тора.

2. Бүлек Татарстан Республикасы Рәисенең Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы бүләкләү законнары өлкәсендәге вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча эшчәнлеген тәэмин итү максатларында төзелде.

3. Бүлек үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Рәисе указларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе турында нигезләмәгә, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе боерыкларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

4. Бүлек Татарстан Республикасы Рәисенә һәм Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә буйсына.

5. Бүлек турында нигезләмә Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан раслана.

II. Бүлекнең төп бурычлары

6. Бүлекнең төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан аның Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре (алга таба шулай ук – дәүләт бүләкләре) белән бүләкләүгә, Россия Федерациясе Президентының Мактау грамотасы, Россия Федерациясе Президентының рәхмәте, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең Мактау грамотасы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең рәхмәте, «Хезмәт ветераны» исеме алу хокукын бирә торган ведомство аерымлык тамгалары, Татарстан Республикасы Рәисенең Рәхмәте белән бүләкләүгә (алга таба шулай ук – башка төр бүләкләүләр) кагылышлы

мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрен тормышны ашыруны тәэмин итүдә катнашу;

Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе эшчәнлеген тәэмин итү.

## III. Бүлекнең төп функцияләре

7. Бүлекнең төп функцияләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

дәүләт бүләкләре белән бүләкләү, башка төр бүләкләүләр турындагы документларны карап тикшерү;

Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе утырышында карап тикшерү өчен материаллар әзерләү, аның эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итү;

Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләү, Татарстан Республикасы Рәисенең Рәхмәтен белдерү турында, югалган Татарстан Республикасы бүләкләренең дубликатларын бирү һәм аларны алмаштыру турында Татарстан Республикасы Рәисе указлары һәм боерыклары проектларын һәм тиешле документларны әзерләү;

Россия Федерациясе дәүләт бүләкләре, Россия Федерациясе Президентының Мактау грамотасы, Россия Федерациясе Президентының рәхмәте, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең Мактау грамотасы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең рәхмәте, «Хезмәт ветераны» исеме алу хокукын бирә торган ведомство аерымлык тамгалары белән бүләкләү, югалган Россия Федерациясе бүләкләренең дубликатларын бирү һәм аларны алмаштыру турында тиешле документларны әзерләү;

Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан дәүләт бүләкләрен һәм башка төр бүләкләүләрне тапшыруны оештыру;

дәүләт бүләкләре һәм башка төр бүләкләүләргә кагылышлы мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Рәисе һәм Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе өчен мәгълүмати-аналитик материаллар әзерләүдә катнашу;

Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен гамәлгә кую, бүләкләүләр турындагы законнарга үзгәрешләр кертү һәм аларның үтәлешен контрольдә тоту, бүләкләүләр системасын камилләштерү бәйле материаллар һәм тәкъдимнәр әзерләүдә катнашу;

үз компетенцияләре чикләрендә дәүләт бүләкләренә һәм башка төр бүләкләүләргә кагылышлы федераль законнарның, Россия Федерациясе Президентының указларының, боерыкларының һәм йөкләмәләренең, Татарстан Республикасы законнарының, Татарстан Республикасы Рәисе указларының, боерыкларының һәм йөкләмәләренең үтәлешенә контрольне тормышка ашыру;

дәүләт бүләкләре эскизларына, дәүләт бүләкләре турындагы нигезләмәләр проектларына һәм дәүләт бүләкләре тасвирламаларына экспертиза үткәрүдә катнашу;

дәүләт бүләкләренә һәм башка төр бүләкләүләргә заказ бирү, саклау, аларны исәпкә алу һәм җибәрүне тәэмин итү;

Татарстан Республикасында дәүләт бүләкләре һәм башка төр бүләкләүләр белән бүләкләнүчеләр турында белешмәләрнең электрон базасын булдыру һәм алып бару, дәүләт бүләкләре һәм башка төр бүләкләүләр белән бүләкләнүчеләрне исәпкә алу карточкаларын алып бару, алар буенча белешмәләр туплау эшен оештыру, дәүләт бүләкләреннән мәхрүм ителгән гражданнарны исәпкә алу;

Россия Федерациясе дәүләт бүләкләре һәм Россия Федерациясе Президентының Мактау грамотасы, Россия Федерациясе Президентының рәхмәте белән бүләкләнгән затлар турында мәгълүматны «Республика Татарстан» һәм «Ватаным Татарстан» газеталарында бастырып чыгаруны тәэмин итү;

Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләү, Татарстан Республикасы Рәисенең Рәхмәтен белдерү турында Татарстан Республикасы Рәисе указларын һәм боерыкларын Татарстан Республикасы Рәисенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгаруны тәэмин итү;

Бүлек компетенциясенә кергән мәсьәләләр буенча аналитика һәм мәгълүмати эш алып бару һәм Россия Федерациясе Президентының Дәүләт бүләкләре буенча идарәсенә, Россия Федерациясе Президентының Идел буе федераль округындагы вәкаләтле вәкиле аппаратына, Татарстан Республикасы буенча баш федераль инспектор аппаратына тиешле материалларны әзерләү;

расланган эшләр номенклатурасы нигезендә бүләкләү документларын архивка тапшыру өчен системалаштыру һәм бүләкләү документларының саклanganлыгын тәэмин итү;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе хезмәткәрләренә, Татарстан Республикасы дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының җитәкче хезмәткәрләренә Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының бүләкләүләр турындагы законнары, шулай ук башка төр бүләкләүләр турында норматив хокукый актлар таләпләрен үтәү мәсьәләләре буенча консультация бирү һәм методик ярдәм күрсәтү;

Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының бүләкләүләр турындагы законнарын һәм башка төр бүләкләүләр турында норматив хокукый актлар таләпләрен үтәүгә кагылышлы мәсьәләләр буенча гражданнарны кабул итүне оештыру;

үз компетенцияләре чикләрендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү, алар буенча карарлар кабул итү һәм законнарда билгеләнгән срокларда җавапларны юллау.

Бүлек Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе кушуы буенча башка функцияләрне башкара.

## IV. Бүлекнең хокуклары

8. Бүлек үз бурычларын һәм функцияләрен тормышка ашыру өчен түбәндәгеләргә хокуклы:

билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең структур бүлекчәләреннән, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратыннан, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратыннан, Татарстан Республикасының башка дәүләт органнарыннан, федераль дәүләт органнарыннан һәм аларның территориаль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, шулай ук оешмалардан һәм вазыйфаи затлардан тиешле мәгълүмат һәм материалларны соратып алырга;

билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмати системаларындагы мәгълүматлардан файдаланырга;

билгеләнгән тәртиптә дәүләт элемтә һәм коммуникация системаларыннан файдаланырга;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе белән килештереп, Россия Федерациясе законнары нигезендә аерым эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен фән һәм мәгариф оешмаларын, шулай ук галимнәрне һәм белгечләрне җәлеп итәргә.

## V. Бүлекнең хезмәттәшлек итү даирәсе

9. Бүлек үзенә йөкләнгән функцияләрне гамәлгә ашырганда Россия Федерациясе Президентының Дәүләт бүләкләре буенча идарәсе, Россия Федерациясе Президентының Идел буе федераль округындагы вәкаләтле вәкиле аппараты, Татарстан Республикасы буенча баш федераль инспектор аппараты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, Татарстан Республикасының башка дәүләт органнары, федераль дәүләт органнары һәм аларның территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм вазыйфаи затлар, шулай ук Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең барлык структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи затлары белән хезмәттәшлек итә.

## VI. Җаваплылык

10. Бүлек хезмәткәрләре Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе тарафыннан расланган вазыйфаи регламентлар нигезендә аларга йөкләнгән бурычларны үтәү өчен җаваплы була.

## VII. Бүлек эшчәнлеген оештыру

11. Бүлекнең структурасы һәм штат саны Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан раслана.

12. Бүлек эшчәнлегенә Татарстан Республикасы Рәисе боерыгы нигезендә вазыйфага билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә торган Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең дәүләт бүләкләре бүлеге мөдире (алга таба – Бүлек мөдире) җитәкчелек итә.

13. Бүлек мөдире:

Бүлек эшен оештыра, Бүлеккә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен җаваплы була;

Бүлекнең төп эшчәнлеген планлаштыруны оештыра;

үз компетенцияләре чикләрендә документларга кул куя һәм имза сала;

Бүлек хезмәткәрләре арасында вазыйфаи бурычларны бүлә һәм аларның вазыйфаи регламентларын Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә раслауга бирә;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе каравына Бүлекнең структурасы, штат саны, Бүлек хезмәткәрләрен вазыйфага билгеләп кую һәм вазыйфадан азат итү турында тәкъдимнәр бирә;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә Бүлек хезмәткәрләрен бүләкләү яисә аларны дисциплинар җәзага тарту турында тәкъдимнәр бирә;

Бүлек компетенциягә караган мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Рәисе һәм Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе белән фикер алышуларда катнаша;

Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе кушуы буенча Татарстан Республикасы дәүләт органнары уздырган коллегия утырышларында, киңәшмәләрдә катнаша, билгеләнгән тәртиптә Бүлек вәкилләрен коллегия утырышларында һәм киңәшмәләрдә катнашырга җибәрә.

14. Бүлек мөдире вакытлыча эш урынында булмаган чорда аның вазыйфаларын Бүлекнең вәкаләтле вазыйфаи заты башкара.

15. Бүлек хезмәткәрләре Бүлек мөдире тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе тарафыннан вазыйфага билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә.

___________